**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлегенең Мостафин авылы торак пунктында
2022 елда үзара салым кертү турында

**2021 елның 16 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең Мостафин авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге Мостафин авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидларыннан, 80 яшьтэн олкэннэрдэн, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Мостафин авылында урамнарны яктырту лампаларын ремонтлау, сатып алу һәм алыштыру;
- Беларус тракторын карап тоту-82,1 (машина йөртүченең эш хакы, запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу);
- Мостафин авылында чишмэ тозеклэндере, төзелеш материаллары сатып алу;
- Мостафин авылына обелиск ясау, аны урнаштыру һәм аларның эшләренә түләү;
- шлагбаумнар ясау өчен төзелеш материаллары сатып алу;

3. Әлеге карарны Петровский Завод авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче А.Б. Хөснетдинов